ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 сентябрь 2017 ел № 5755

Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасының региональ сегментын формалаштыру максатында, пункты нигезендә, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 номерлы карарына, түбәндәге редакциядә 2.1 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«2.1. Башкарма комитетның районнар Хакимиятләре Башлыкларына тәэмин итәргә:

1) социаль ярдәм чараларыннан файдаланучылар турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән җибәрүне;

2) мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы билгеләгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән алуны.».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин